Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты

422000,ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, РТ, г. Арск, площадь Советская ,27
тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

17 апрель 2023 ел № 64

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Айван авылында йортлар төзелеше кварталын планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына, Арча шәһәр Советының 17.08.2022 №73 карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Арча шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Айван авылында йортлар төзелеше кварталын планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты –2023 елның 18 мае, 17.00;

2.2. Үткәрү урыны - Арча шәһәре башкарма комитетының административ бинасы;

2.3. Фикер алышу мәсьәләсе буенча, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү тәкъдимнәр тәкъдим ителә торган адрес:

РТ, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 (эш көннәрендә 08.00 дән 17.00 гә кадәр);

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты -2023 елның 18 маена кадәр (тел. 3-16-25).

3. Күрсәтелгән мәсьәлә буенча әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә һәм карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арча шәһәре
башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймов